ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 46-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Н.Н. Хаҗипов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 46-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 201-VII ДС

46-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
А.К. Хамаев,
Н.Н. Хажипов тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6 – 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 1; 2011, № 11 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш), 2023, № 20 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 өлешендәге өченче абзацында «ветеринария-санитария ягыннан» сүзләрен «ветеринария ягыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15) «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $19^2$ статьясындагы 3 пунктында (алга таба – «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законы) күрсәтелгән очраклардан тыш, ветеринария күзәтчелеге өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан зоосанитария статусын билгеләүдә катнашу»

3) 18 статьяда:

а) 1 өлештә:

дүртенче абзацта «терлекләрне күчерүнең һәм чалуның, терлек продукциясен эшкәртүнең, саклауның һәм сатуның билгеләнгән ветеринария-санитария кагыйдәләрен» сүзләрен «ветеринария кагыйдәләрен» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «ветеринария-санитария ягыннан» сүзләрен «ветеринария ягыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «ветеринария-санитария ягыннан» сүзләрен «ветеринария ягыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) 19 статьяда:

а) 1 өлештә татарча текст үзгәрми;

б) 2 өлештә татарча текст үзгәрми.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 1 – 3 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 – 3 пунктлары 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты республика законын федераль законнарга туры китерү максатларында әзерләнде, бу зарурлык «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертелгән кайбер федераль законнар кабул ителүгә бәйле барлыкка килде.

Биологик калдыклар белән эш итү, үләт базларын эксплуатацияләү һәм юкка чыгару мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 582-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының 19 статьясы нигезләмәләренә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продукциясен хуҗаларыннан алу мәсьәләләрен җайга сала торган төзәтмәләр кертелде.

«Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына һәм «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 26 декабрендәге 496-ФЗ номерлы Федераль закон белән законнарда кулланыла торган терминологиягә төзәтмәләр кертелде.

«Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $2^7$ һәм $19^2$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 556-ФЗ номерлы Федераль закон белән зоосанитария статусын билгеләү өлешендә Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнарының вәкаләтләренә төзәтмәләр кертелде. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законында федераль законнардагы күрсәтелгән үзгәрешләрен чагылдырырга кирәк.

**«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.